ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: : Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

15 ноября 2019 года № 26

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә гражданнарныңүзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге гражданнарының карарларын тормышка ашыру максатыннан
2019 нчы елның 13 ноябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Васильево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 нчы елның 14 ноябрендә кабул ителгән 2 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Ишки авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты;
К а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Советы рәисе /Р.К.Хафизов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Ишки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
15.11 2019 ел, 26 санлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2020 елның 26 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәттә катнашучыларның толлары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар
теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге
Башкарма комитетының 15.11. 2019 ел,
26 санлы карарына 2 нче кушымта

Ишки авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________________
________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2020 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2020 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ______ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: __________________________________________________
Кабул итүче як банкы БИК _____________________________________
Сч. № __________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче ________________ ________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

_______________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________________
_
«__» ______________ 20__ г. _____________________________________
(түләүченең имзасы)